**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларына һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнары Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүне камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-550 номерлы, 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-664 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы, 2023 елның 12 гыйнварындагы ПУ-10 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 маендагы 333 номерлы, 2023 елның 13 июлендәге 490 номерлы, 2023 елның 22 августындагы 575 номерлы, 2023 елның 2 декабрендәге 828 номерлы һәм 2024 елның 10 маендагы 335 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларына, «****» символы белән билгеләнгән астөшермәнең өченче абзацына «, Тукай муниципаль районы» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның

3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы, 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-665 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 10 маендагы 336 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларына, «*» символы белән билгеләнгән астөшермәнең өченче абзацына «, Тукай муниципаль районы» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 18 сентябрь
№ 725